# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Ковали авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2025 елның 15 ноябре** **№ 8**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 15 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Кавали авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда үзара салымны 2000,00 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 100 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 58 кеше кертелде, бу 58% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 58 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Кавали авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең Берновые Кавали авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда үзара салымны 2000,00 сум

күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Бишнә авыл җирлегенең Берновые Кавали авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын 2000,00 сум күләмендә кертергә.

4. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

5. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлегенең Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 йорт (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Мәктәп урамы, 10 йорт (Бишнә мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М.Фатхуллин